ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МЕНДЕЛЕЕВСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
АБАЛАЧ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
ТАГАЙ АВЫЛЫНДА ХАЛЫК ҖЫЕНЫ

РЕШЕНИЕ КАРАР

2019 елның 30 ноябреннән № 1

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Абалач авыл җирлегенең Тагай авылында гражданнар җыены КАРАР ИТТЕ:

1. 2020 елда Менделеевск муниципаль районы Абалач авыл җирлегенең Тагай авылында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым акчаларын кертергә, I һәм II төркем инвалидларын һәм Бөек Ватан сугышында катнашучыларны, Бөек Ватан сугышы ветераннарының тол хатыннарын, тыл хезмәтчәннәрен, көндезге уку бүлеге студентларын төшереп калдырырга, ә күпбалалы һәм III төркем инвалидларына - бер тапкыр бирелә торган түләүне киметеп һәм әлеге категориядәге гражданнар өчен 250 сум күләмендә билгеләргә.
2. Алынган акчаларны Тагай авылы эчендәге юлларны карап тоту буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерергә (кышкы чорда кардан чистарту)
3. Абалач авылының мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән гражданнар җыены нәтиҗәләрен игълан итәргә һәм Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтында www.mendeleevsk.tatar.ru «Абалач авыл җирлеге» бүлегендә урнаштырырга.
4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Абалач авыл җирлеге башлыгы И.Ш. Исрафилов